Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Югары Симет авыл җирлеге Югары Симет торак пунктында

# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

29.10.2020 № 2

06.10.2003 ел, № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» гы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Саба муниципаль районы Югары Симет авыл җирлеге Уставының 22 нче маддәсенә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Югары Симет авыл җирлеге Советының 25.10.2009 ел, № 19 номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Югары Симет авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында " карарына таянып, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Югары Симет авыл җирлегенең Югары Симет торак пункты территориясендә халык җыены карар итте:

1. 2021 нче елда Саба муниципаль районының Югары Симет авыл җирлеге Югары Симет торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 600 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

- Югары Симет авылы чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлау.

3.Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Саба муниципаль районы Югары Симет авыл җирлегенең рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http://saby.tatarstan.ru/simet бастырып чыгарырга.

Югары Симет авыл җирлеге башлыгы И.Р.Әхмәдуллин